3. Муниципаль тышкы хисаплашулар чираттагы финанс елына һәм план чорына Россия Федерациясенең тышкы дәүләт хисаплашулары программасына кертелгән проектларны финанслау максатларында гамәлгә ашырыла.

4. Россия Федерациясе Бюджет кодексы һәм Район уставы нигезендә Район исеменнән муниципаль хисаплашуларны гамәлгә ашыру хокукына җирле администрация (Районның башкарма-боеру органы) ия була.

5. Муниципаль кыйммәтле кәгазьләрне урнаштыру түбәндәге шартларны үтәгәндә Район тарафыннан гамәлгә ашырыла:

1) Районның бурыч йөкләмәләре буенча кичектерелгән бурычлары булмау;

2) Районның кредит рейтингы Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнә торган дәрәҗәдән ким булмау, бер яисә берничә рейтинг гамәлен башкаручы юридик затлар исемлеге Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнә.

6. Россия Федерациясе Бюджет кодексының 1071 статьясы һәм Татарстан Республикасы Бюджет кодексының 311 статьясы нигезендә Районны бурыч тотрыклылыгының уртача дәрәҗәсе булган заемчылар төркеменә керткән очракта, Район муниципаль хисаплашулар башкарырга, Россия Федерациясе Бюджет кодексының 1071 статьясындагы 5 пунктында каралган Районның бурыч тотрыклылыгы күрсәткечләрен бурыч тотрыклылыгының дәрәҗәсе түбән булган заемчылар төркеменә кертүгә китерә торган күләмнәргә кадәр муниципаль гарантияләр бирергә хокуклы түгел.

7. Район, Россия Федерациясе Бюджет кодексының 1071 статьясы һәм әлеге Кодексның 311 статьясы нигезендә бурыч тотрыклыгының уртача дәрәҗәсенә ия булган заемчылар төркеменә кергән очракта, чираттагы финанс елына һәм план чорына (чипаттагы финанс елына) муниципаль эчке һәм тышкы дәүләт хисаплашулары, муниципаль гарантияләр программаларын, шулай ук күрсәтелгән программаларга үзгәрешләрне бары тик Татарстан Республикасы Финанс

министрлыгы белән килештергән очракта, муниципаль хисаплашуларын гамәлгә ашырырга, муниципаль гарантияләр бирергә хокуклы.

8. Россия Федерациясе Бюджет кодексының 1071 статьясы һәм әлеге Кодексның 311 статьясы нигезендә бурыч тотрыклыгының түбән дәрәҗәсенә ия булган заемчылар төркеменә кергән очракта, Район муниципаль хисаплашулар башкарырга, Россия Федерациясе Бюджет кодексының 1071 статьясындагы 5 пунктында каралган Районның бурыч тотрыклылыгы күрсәткечләрен бурыч тотрыклылыгының дәрәҗәсен күтәрүгә китерә торган күләмнәргә кадәр муниципаль гарантияләр бирергә хокуклы түгел.

9. Район Россия Федерациясе Бюджет кодексының 1071 статьясы һәм әлеге Кодексның 311 статьясы нигезендә Район бурыч тотрыклылыгы түбән дәрәҗәдә булган заемчылар төркеменә кертелгән очракта, эчке муниципаль хисаплашуларын Районның кыйммәтле кәгазьләрен бары тик рефинанслау максатларында гына, кредит оешмаларыннан кредитлар рәвешендә һәм җирлекнең кыйммәтле кәгазьләрен урнаштыру юлы белән, шулай ук Россия Федерациясе Бюджет кодексының 1071 статьясындагы 9 пунктында һәм әлеге Кодексның 311 статьясындагы 7 пунктында каралган Районның түләү сәләтен торгызу планы кысаларында Россия Федерациясе бюджет системасының башка бюджетларыннан бирелгән максатчан бюджет кредитлары рәвешендә гамәлгә ашырырга хокуклы.

10.Район Россия Федерациясе Бюджет кодексының 1071 статьясы һәм әлеге Кодексның 311 статьясы нигезендә бурыч тотрыклылыгы түбән дәрәҗәдә булган заемчылар төркеменә кертелгән очракта, муниципаль тышкы хисаплашуларны гамәлгә ашырырга һәм муниципаль гарантияләрне чит ил валютасында бирергә хокуксыз була.

11. Район Россия Федерациясе Бюджет кодексының 1071 статьясы һәм әлеге Кодексның 311 статьясы нигезендә бурыч тотрыклыгы түбән дәрәҗәдә булган заемчылар төркеменә кергән очракта, Россия Федерациясе валютасында чираттагы финанс елына һәм план чорына муниципаль эчке хисаплашулар, муниципаль гарантияләр программаларны оссия Федерациясе валютасында чираттагы финанс елына һәм план чорына (чираттагы финанс елына) эчке һәм тышкы муниципаль хисаплашулар, муниципаль гарантияләр программаларын), шулай ук күрсәтелгән программаларга үзгәрешләрне бары тик Россия Федерациясе Финанс министрлыгы (Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы) белән килештергән очракта гына, дәүләт (муниципаль) хисаплашуларын гамәлгә ашырырга, дәүләт (муниципаль) гарантияләрен бирергә хокуклы.

12. Россия Федерациясе Бюджет кодексының 1071 статьясындагы 9 пунктында каралган Районның түләү сәләтен торгызу планы кысаларында Россия Федерациясе бюджет системасының башка бюджетларыннан бирелгән максатчан бюджет кредитлары буенча Район йөкләмәләренә реструктуризацияләү уздыру рөхсәт ителми.

**21 статья. Район тарафыннан чит ил валютасында хисаплашулар һәм гарантияләр бирү үзенчәлекләре**

1. Район Россия Федерациясеннән чит ил валютасындагы хисаплашуларны гамәлгә ашырырга, Россия Федерациясеннән, Россия Федерациясе Бюджет кодексының 103 статьясындагы 25 пункты нигезләмәләрен исәпкә алып, җәлеп ителгән максатчан чит ил кредитлары акчаларын Россия Федерациясе тарафыннан куллану кысаларында гына чит ил валютасында гарантияләр бирергә хокуклы.

**22 статья. Муниципаль бурыч алуларның чик күләме**

1. Тиешле финанс елына муниципаль бурыч алуларның чик күләме дип тиешле финанс елына муниципаль эчке һәм тышкы бурыч алулар программалары буенча җирле бюджетка акча җәлеп итүнең җыелма күләме аңлашыла.

2. Җирле бюджетка акча җәлеп итү күләме чираттагы финанс елына һәм план чорына (чираттагы финанс елына) муниципаль эчке һәм тышкы бурыч алулар программалары белән билгеләнә, һәм тиешле финанс елында акчаларны җәлеп итүнең гомуми суммасы, Россия Федерациясе Бюджет кодексының 103 һәм 104 статьялары нигезләмәләрен исәпкә алып, җирле бюджет кытлыгын финанслауга җибәрелә торган акчаларның гомуми суммасыннан һәм җирле

бюджет турында тиешле финанс елына расланган Район бурыч йөкләмәләрен түләү күләмнәреннән артмаска тиеш.

3. Финанс хисабы елында Район хисаплашуларының гомуми суммасы җирле бюджет кытлыгын финанслауга юнәлдерелгән акчаларның һәм финанс хисабы елы йомгаклары буенча агымдагы елның 1 гыйнварына барлыкка килгән Районның бурыч йөкләмәләрен түләү күләмнәренең гомуми суммасыннан артып киткән очракта, күрсәтелгән арттыру суммасында җирле бюджет акчаларының калдыклары Россия Федерациясе Бюджет кодексының 96 статьясында каралган максатларга, агымдагы финанс елына хисаплашуларның иң чик күләмен киметеп, юнәлдерелергә тиеш.

**23 статья . Муниципаль эчке һәм тышкы бурычның югары чикләре һәм Районның бурыч тотрыклылыгының чикле күрсәткечләре**

1.Җирле бюджет турында карар белән чираттагы финанс елыннан һәм план чорының һәр елыннан соң килә торган елның 1 гыйнварына (чираттагы финанс елыннан соң килә торган елның 1 гыйнварына), шул исәптән Россия Федерациясе валютасында муниципаль гарантияләр буенча, чит ил валютасында муниципаль гарантияләр буенча (Районның чит ил валютасында муниципаль гарантияләр буенча йөкләмәләре булган очракта) бурычның иң югары чиген күрсәтеп, эчке муниципаль бурычның, тышкы муниципаль бурычның (Районның чит ил валютасында йөкләмәләре булган очракта) иң югары чикләре билгеләнә.

2. Муниципаль эчке бурычның, муниципаль тышкы бурычның югары чикләре (районның чит ил валютасында йөкләмәләре булганда) әлеге статьяның 4 һәм 5 пунктларында билгеләнгән чикләүләрне үтәгәндә билгеләнә.

3. Муниципаль бурыч күләме чираттагы финанс елына һәм план чорына (чираттагы финанс елына) җирле бюджет турындагы карар нигезендә расланган, кире кайтарылмый торган кертемнәрнең һәм (яисә) физик затлар керемнәренә салымнан түләүләрнең өстәмә нормативлары буенча салым керемнәреннән түләүләрнең расланган күләмен исәпкә алмыйча, җирле бюджет керемнәренең гомуми күләменнән артмаска тиеш.

Районга карата Россия Федерациясе Бюджет кодексының 136 статьясындагы 4 пунктында каралган чараларны гамәлгә ашырган очракта, бурыч күләме чираттагы финанс елына һәм план чорына (чираттагы финанс елына) җирле бюджет керемнәренең гомуми күләменнән, физик затлар керемнәренә салымнан түләүләрнең өстәмә нормативлары буенча, кире кайтарылмый торган кертемнәрнең һәм (яисә) салым керемнәренең расланган күләмен исәпкә алмыйча, җирле бюджет керемнәренең гомуми күләменең 50 процентыннан артмаска тиеш.

4. Муниципаль бурычка хезмәт күрсәтү чыгымнары күләме түбәндәге таләпләрне үтәгәндә җирле бюджет турындагы карар белән расланa:

1) чираттагы финанс елында һәм план чорында (чираттагы финанс елында) муниципаль бурычка хезмәт күрсәтүгә чыгымнар күләме җирле бюджет чыгымнарының гомуми күләменең чираттагы финанс елына һәм план чорына (чираттагы финанс елына) җирле бюджет турында карар белән расланган 10 процентыннан артмаска тиеш, моңа Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларыннан бирелә торган субвенцияләр исәбеннән башкарыла торган чыгымнар күләме керми;

2) чираттагы финанс елында һәм план чорында чираттагы финанс елының 1 гыйнварына муниципаль бурычны каплау һәм аңа хезмәт күрсәтү буенча барлыкка килгән түләүләрнең еллык суммасы чираттагы финанс елына һәм план чорына (чираттагы финанс елына) җирле бюджет турындагы карар белән расланган җирле бюджетның салым, салым булмаган керемнәре һәм Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларыннан дотацияләрнең еллык күләменнән 20 процентка артмаска тиеш; күрсәтелгән нисбәтне исәплгәндә чираттагы финанс елыннан һәм план чорының һәр елыннан соң килә торган елның 1 гыйнварыннан соң каплана торган бурыч йөкләмәләрен вакытыннан алда каплауга җибәрелә торган түләүләр суммасы исәпкә алынмый.

**24 статья. Чит ил валютасында муниципаль гарантияләр программасы**

1. Чит ил валютасындагы муниципаль гарантияләр программасы чираттагы финанс елында һәм план чорында бирелә торган чит ил валютасындагы муниципаль гарантияләрнең түбәндәге белешмәләрне күрсәтеп исемлегеннән гыйбарәт:

һәр юнәлеш (максат), категория (төркем) һәм (яисә) гарантиянең һәр юнәлеше (максаты) буенча принципаллар атамалары буенча күрсәтеп гарантияләр күләмен күрсәтеп, гарантияләү юнәлешләре (максатлары);

2) гарантияләр һәм алар белән тәэмин ителә торган йөкләмәләр валютасы;

3) гарантияләрнең гомуми күләме;

4) гарантның принципалларга карата регресс таләбе хокукы булу (булмау) ;

5) гарантияләрне бирү һәм үтәүнең башка шартлары.

2. Муниципаль гарантия муниципаль гарантия белән тәэмин ителә торган йөкләмәләр белдерелгән валютада бирелә һәм үтәлә.

3. Чит ил валютасындагы муниципаль гарантияләр программасы бюджет турындагы тиешле карарга кушымта булып тора.

**25 статья. Муниципаль тышкы хисаплашулар программасы**

1. Чираттагы финанс елына һәм план чорына (чираттагы финанс елына) муниципаль тышкы хисаплашулар программасы чираттагы финанс елында һәм план чорында (чираттагы финанс елында) максатчан чит ил кредитларыннан файдалану кысаларында федераль бюджеттан җирле бюджетка чит ил валютасында җәлеп ителә торган һәм (яисә) түләнә торган бюджет кредитлары исемлегеннән гыйбарәт.

2. Муниципаль тышкы хисаплашулар программасы белән түбәндәгеләр билгеләнә:

1) чираттагы финанс елында һәм план чорында (чираттагы финанс елында) максатчан чит ил кредитларыннан файдалану кысаларында җирле бюджетка акчалар җәлеп итү күләме һәм федераль бюджеттан җирле бюджетка чит ил валютасында җәлеп ителә торган бюджет кредитлары буенча барлыкка килә торган бурыч йөкләмәләрен каплау сроклары;

2) чираттагы финанс елында һәм план чорында (чираттагы финанс елында) максатчан чит ил кредитларыннан файдалану кысаларында җирле бюджетка федераль бюджеттан чит ил валютасында җәлеп ителгән бюджет кредитлары буенча Районның йөкләмәләрен каплау күләме.

3. Чираттагы финанс елына һәм план чорына (чираттагы финанс елына) муниципаль тышкы хисаплашулар программасы чираттагы финанс елына һәм план чорына (чираттагы финанс елына) җирле бюджет турында карарга кушымта булып тора.

**26 статья. Муниципаль эчке хисаплашулар программасы**

1. Чираттагы финанс елына һәм план чорына (чираттагы финанс елына) муниципаль эчке хисаплашулар программасы чираттагы финанс елында һәм план чорында (чираттагы финанс елында) түләнелә торган һәм (яисә) юкка чыгарыла торган тиешле бурыч йөкләмәләре төрләре буенча муниципаль эчке хисаплашулар исемлегеннән гыйбарәт.

2. Муниципаль эчке хисаплашулар программасы белән түбәндәгеләр билгеләнә:

1)чираттагы финанс елында һәм план чорында җирле бюджет бюджетына акчаларны җәлеп итү күләмнәре һәм муниципаль эчке хисаплашуларын гамәлгә ашырганда бурыч йөкләмәләре төрләре буенча барлыкка килә торган бурыч йөкләмәләрен каплауның иң чик сроклары;

2) Россия Федерациясе валютасында белдерелгән муниципаль бурыч йөкләмәләрен тиешле бурыч йөкләмәләре төрләре буенча түләү күләмнәре.

3. Чираттагы финанс елына һәм план чорына (чираттагы финанс елына) муниципаль эчке хисаплашулар программасы чираттагы финанс елына һәм план чорына (чираттагы финанс елына) тиешле бюджет турында карарга кушымта булып тора.

4. Россия Федерациясе Бюджет кодексының 105 статьясы нигезендә муниципаль эчке бурыч үткәрү муниципаль эчке хисаплашулар программасында чагылдырылмый.

**27 статья. Россия Федерациясе валютасында муниципаль гарантияләр программасы**

1. Россия Федерациясе валютасында муниципаль гарантияләрнең программасы чираттагы финанс елында һәм план чорында бирелә торган Россия Федерациясе валютасында муниципаль гарантияләрнең түбәндәге белешмәләрне күрсәтеп бирелә торган исемлегеннән гыйбарәт:

һәр юнәлеш (максат), категория (төркем) һәм (яисә) гарантиянең һәр юнәлеше (максаты) буенча принципаллар атамалары буенча күрсәтеп гарантияләр күләмен күрсәтеп, гарантияләү юнәлешләре (максатлары);

2) гарантияләрнең гомуми күләме;

3) гарантның принципалларга карата регресс таләбе хокукы булу (булмау);

4) гарантияләрне бирү һәм үтәүнең башка шартлары.

2. Россия Федерациясе валютасында белдерелгән йөкләмәләр буенча муниципаль гарантияләре бары тик Россия Федерациясе валютасында гына бирелә һәм үтәлә.

3. Россия Федерациясе валютасындагы муниципаль гарантияләр программасы бюджет турындагы тиешле карарга кушымта булып тора.

**28 статья. Муниципаль кыйммәтле кәгазьләрне урнаштыруның иң чик күләмнәре**

Чираттагы финанс елына һәм план чорының һәр елына (чираттагы финанс елына) муниципаль кыйммәтле кәгазьләрнең иң чик күләме номиналь бәя буенча тиешле бюджет турында карарда билгеләнгән муниципаль эчке бурычның югары чикләреннән тыш Район Советы тарафыннан билгеләнә.

**29 статья. Муниципаль гарантияләр**

1. Муниципаль гарантия принципалның бенефициар каршында шартнамәдән (договордан) яисә башка алыш-бирештән (төп йөкләмәдән) барлыкка килгән акчалата йөкләмәләрен тиешенчә үтәүне тәэмин итә.

2. Муниципаль гарантия, принципал йөкләмәләрен вакытыннан алда үтәүне, принципалга аларның вакытыннан алда үтәлеше турында таләпләр куелган очракта да яки принципал йөкләмәләрен үтәү вакыты җитүенә этәргеч булган вакыйгалар туган очракта да тәэмин итми.

3. Муниципаль гарантиянең язма формасы мәҗбүри булып тора.

4. Муниципаль гарантия төп йөкләмә суммасы чагылдырылган валютада бирелә һәм үтәлә.

5. Муниципаль гарантия буенча гарант принципалның үзенә тәэмин ителгән йөкләмәсе буенча гарантия суммасы чикләрендә субсидиар җаваплылык тота.

6. Муниципаль гарантиядә түбәндәгеләр күрсәтелә:

1) Гарант исеме (тиешле гавами-хокукый берәмлек– Район) һәм гарант исеменнән гарантия биргән орган исеме;

2) бенефициарның исеме;

3) принципалның исеме;

4) гарантия бирелә торган йөкләмә (төп йөкләмәнең исемен, бәяләмәсен һәм номерын (булган очракта), төп йөкләмәнең гамәлдә булу вакытын яисә аның буенча йөкләмәләрне үтәү вакытын, якларның исемнәрен, төп йөкләмәнең башка мөһим шартларын күрсәтеп);

5) гарант йөкләмәләре күләме һәм гарантиянең иң чик суммасы;

6) гарантия бирүнең нигезләре;

7) гарантия үз көченә керү датасы яисә гарантия үз көченә керү өчен этәргеч булган вакыйга (шарт);

8) гарантиянең гамәлдә булу срогы;

9) гарантия очрагын билгеләү, гарантия үтәлеше турында бенефициар таләбен кую вакыты һәм тәртибе;

10) гарантияне кире алу нигезләре;

11) гарантия буенча йөкләмәләрне гарант тарафыннан үтәү тәртибе;

12) гарантиянең тулы күләмдә яисә нинди дә булса өлешендә үтәлгәндә, принципалның гарантия белән тәэмин ителгән йөкләмәләренең тулы күләмдә яисә нинди дә булса өлешендә үтәлгәндә (туктатылганда) һәм гарантиядә билгеләнгән башка очракларда гарантия суммасын киметү нигезләре;

13) гарантияне туктату нигезләре;

14) гарантның алдан язма ризалыгыннан башка үзгәртелә алмый торган төп йөкләмә шартлары;

15) муниципаль гарантия буенча бенефициарга гарант тарафыннан түләнгән акчаларны каплау турында принципалга гарант таләбе хокукы булу яисә булмау (принципалга карата гарантның регресс таләбе, регресс);

16) гарантиянең башка шартлары, шулай ук Россия Федерациясе Бюджет кодексында, гарантның норматив хокукый актларында, гарант исеменнән гарантия бирүче орган актларында билгеләнгән белешмәләр.

7.Гарантның принципалга карата регресс таләбе хокукын күздә тотмый торган муниципаль гарантия, бары тик район милкендә булган муниципаль гарантия бирә торган һәм район милкендә 100 процент акцияләре булган хуҗалык җәмгыяте йөкләмәләре буенча гына бирелә ала. Принципалны тулысынча яисә өлешчә хосусыйлаштырган очракта, мондый муниципаль гарантия принципалга карата гарантның регресс таләбе хокукы белән бирелгән дип санала һәм, гарантиянең тулы күләмендә яисә бер өлешендә үтәлүенә бәйле рәвештә барлыкка килә торган принципалга карата Россия Федерациясе Бюджет кодексының 1153 статьясы һәм Россия Федерациясе граждан законнары таләпләренә туры килә торган, Районның җирле администрациясе актларында билгеләнгән срокта гарантның регресс таләбен канәгатьләндерү буенча принципалның үтәлүен тәэмин итү бурычы барлыкка килә. Күрсәтелгән тәэмин итүне тапшырганчы муниципаль гарантияне үтәү рөхсәт ителми.

8. Муниципаль гарантиянең үз көченә керүе календарь дата яисә гарантиядә күрсәтелгән билгеле бер вакыйга (шартлар) башлану белән билгеләнә.

9. Гарант бенефициарның алдан язма рөхсәтеннән башка муниципаль гарантия шартларын үзгәртергә хокуклы түгел.

10. Муниципаль гарантия буенча бенефициарның гарантка карата булган таләпләр, яңа хуҗага (сатып алучыга) облигациягә хокукларның яңа хуҗасына (эмитентка) күчүгә, принципал (эмитентның) йөкләмәләрен үтәүгә бәйле рәвештә, кыйммәтле кәгазьләр турында Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән таләпләрнең хокукларын тапшырудан (күчүдән) тыш, алдан язма ризалыгыннан башка (башка нигезләр буенча күчәргә) тапшырыла алмый.

11. Муниципаль гарантия гарантиядә күрсәтелгән очракларда һәм нигезләр (шул исәптән әлеге статьяның 6 пунктындагы 14 пунктчасында күрсәтелгән гарантның язма ризалыгыннан башка үзгәртелгән очракта), шулай ук бу статьяның 7 пунктында һәм Россия Федерациясе Бюджет кодексының 1153 статьясындагы 5 пунктында билгеләнгән бурыч принципалы үтәлгәндә Гарант тарафыннан танылa.

12. Муниципаль гарантия буенча акча түләү турында бенефициар таләбе (гарантия үтәлеше турында бенефициар таләбе) гарантиядә билгеләнгән очракта гына (гарантияле очрак барлыкка килгәндә) гарантка бирелергә мөмкин. Гарантия үтәлеше турында бенефициар таләбе гарантиядә билгеләнгән тәртиптә, гарантиядә күрсәтелгән документларны кушып, язма рәвештә гарантка белдерелергә тиеш.

13. Бенефициар муниципаль гарантиядә һәм муниципаль гарантияне бирү турындагы килешүдә билгеләнгән срогыннан элек гарантияне үтәү турында таләпләрне, шул исәптән принципалның гарантиясе белән тәэмин ителгән йөкләмәләрне үтәү срогын якынайта торган вакыйгалар (шартлар) вакытында да, күрсәтергә хокуклы түгел.

14. Гарант гарантия үтәлеше турында бенефициар таләбен кую турында принципалга хәбәр итәргә һәм принципалга таләпнең күчермәсен тапшырырга тиеш.

15. Гарант муниципаль гарантиядә билгеләнгән срокта, бенефициарның күрсәтелгән таләпкә кушып бирелгән документлар белән гарантия үтәлеше турындагы таләбен карарга һәм гарантия шартларына таләпләр һәм аңа кушып бирелгән документлар туры килү-килмәвен тикшерергә тиеш.

16. Түбәндә күрсәтелгән очракларда гарантия үтәлеше турында бенефициар таләбе һәм аңа кушып бирелгән документлар гарантия шартларына туры килми дип танылa һәм гарант бенефициарга аның таләбен канәгатьләндерүдән баш тарта:

1) таләп һәм (яисә) аңа кушып бирелгән документлар гарантка гарантия бирелгән срок (гарантиянең гамәлдә булу срогы) тәмамланганнан соң тапшырылганда;

2) таләп һәм (яисә) аңа кушып бирелгән документлар гарантка гарантиядә билгеләнгән тәртипне бозып, тапшырылганда;

3) таләп һәм (яисә) аңа кушып бирелгән документлар гарантия шартларына туры килмәгәндә;

4) бенефициар принципал һәм (яисә) өченче затлар тарафыннан тәкъдим ителгән принципалның гарантия белән тәэмин ителгән йөкләмәләренең тиешле үтәлешен кабул итүдән баш тартканда;

5) әлеге статьяның 7 пунктында һәм Россия Федерациясе Бюджет кодексының 1153 статьясындагы 6 пунктында билгеләнгән очракларда;

6) гарантиядә билгеләнгән башка очракларда.

17. Гарантиянең үтәлеше турында бенефициар таләбе һәм (яисә) аңа кушып бирелгән документлар нигезсез һәм (яисә) муниципаль гарантия шартларына туры килми дип танылган очракта, гарант бенефициарга аның таләбен канәгатьләндерүдән баш тарту турында хәбәр итәргә тиеш.

18. Гарант бенефициар таләбенә каршы принципал тәкъдим итә алырлык каршылыкларны чыгарырга хокуклы. Гарант хәтта принципал каршылыклардан баш тарткан яки үз бурычын таныган очракта да әлеге каршылыкларга хокукын югалтмый.

19. Гарантия үтәлеше турында бенефициар таләбен һәм аңа кушып бирелгән документларны нигезле һәм муниципаль гарантиянең тиешле шартлары дип танылган очракта, гарант гарантия буенча йөкләмәне гарантиядә билгеләнгән вакытта үтәргә тиеш.

20. Гарантның бенефициар каршындагы муниципаль гарантиядә каралган йөкләмәсе, гарантия белән тәэмин ителгән принципалның срогы чыккан йөкләмәләре күләмендә акча түләве белән чикләнә, ләкин ул гарантия суммасыннан да артмый.

21. Гарантның муниципаль гарантия буенча бенефициар алдындагы йөкләмәсе түбәндәге очракларда туктатыла:

1) гарант бенефициарга гарантиядә билгеләнгән күләмдә акча түләгәндә;

2)гарантиядә билгеләнгән вакытның срогы (гарантиянең гамәлдә булу срогы) чыкканнанда;

3) принципал һәм (яисә) өченче затлар тарафыннан принципалның гарантия белән тәэмин ителгән йөкләмәләре үтәлгән очракта яки принципалның күрсәтелгән йөкләмәләре бүтән нигезләр буенча (бенефициар тарафыннан гарантка һәм (яисә) судка бирелгән гарантия үтәлеше турында гарантка карата таләп булу-булмауга карамастан) туктатылганда;

4) гарантка кире кайтарып бирү юлы белән бенефициар үз хокукларыннан баш тартканда һәм (яисә) бенефициарның гарантия буенча гарантны йөкләмәләреннән азат итү турындаыг язма гаризасы булганда, принципал тарафыннан гарантка Россия Федерациясе Бюджет кодексының 1151 статьясында каралган гарантияне кире кайтару нәтиҗәсендә, мондый гарантия буенча бенефициарлар һәм киләчәктә алар барлыкка килү өчен нигезләр булмаган очракта;

5) принципалның гарантия бирелгән йөкләмәсе билгеләнгән срокта барлыкка килмәгәндә;

6) бенефициар гарантка һәм (яисә) судка гарантия үтәү турындагы таләпне күрсәткәннән соң (шул исәптән, принципалны һәм (яисә) бенефициарны бетерү белән бәйле рәвештә) төп йөкләмәне туктатканда яисә аны гамәлдә булмаган килешү дип таныгында;

7) бенефициар тарафыннан башка затка тапшырылган яисә бенефициарга караган башка нигезләр буенча, гарантка карата гарантия буенча таләп хокуклары, төп йөкләмә буенча хокук һәм (яисә) вазыйфаларны биләү хокуклары гарантның алдан язмача ризалыгыннан башка өченче затка күчкәндә (облигациягә хокукларның яңа хуҗага (сатып алучыга) күчүенә бәйле рәвештә кыйммәтле кәгазьләр турында Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән таләпләрне (хокукларын һәм бурычларын) тапшырудан (күчүдән) тыш);

8) принципал тарафыннан башка затка тапшырылган яки принципалга караган башка нигезләр буенча, төп йөкләмә буенча хокуклар һәм (яисә) бурычлар (бурычның) гарантның алдан язма ризалыгыннан башка өченче затка күчкәндә;

9) гарантияләрдә күрсәтелгән очракларда һәм нигезләр буенча гарантияне чакыртып алу нәтиҗәсендә;

10) гарантиядә билгеләнгән башка очракларда.

22. Гарантның гарантия буенча йөкләмәләре туктатылганнан соң бенефициарның гарантияне тотып калу күрсәтелгән гарантия буенча нинди дә булса хокукларны сакламый.

23. Муниципаль гарантияне туктату турында мәгълүматы булган гарант бу хакта бенефициарга һәм принципалга хәбәр итәргә тиеш.

Бенефициар һәм принципал муниципаль гарантияне чакыртып алуга яисә туктатуга китерә торган хәлләрнең килеп чыгуы турында мәгълүм булганда бу хакта гарантка хәбәр итәргә тиеш.

24. Гарант тарафыннан муниципаль гарантияне үтәү гарантның принципалга карата регресс таләбе хокукы барлыкка килүгә китерсә яки бенефициарның принципалга карата таләбе хокукларының гарантка юл куюы белән бәйле булса, мондый муниципаль гарантияне үтәү өчен акча тиешле бюджет кытлыгын финанслау чыганакларында исәпкә алына, ә мондый муниципаль гарантия буенча йөкләмәләрне үтәү бюджет кредиты бирү буларак чагыла.

25. Әгәр гарант тарафыннан муниципаль гарантияне үтәү гарантның принципалга карата регресс таләбе хокукы барлыкка килүгә китермәсә яки бенефициарның принципалга карата таләп хокукы гарантка юл кую белән бәйле булмаса, мондый муниципаль гарантияне үтәү өчен акча тиешле бюджет чыгымнарында исәпкә алына.

26. Гарант тарафыннан, гарантия буенча йөкләмәләрнең тулы күләмдә яисә нинди дә булса өлешен үтәү йөзеннән, түләнгән акчалар регрессы тәртибендә гарантка кайтару яисә гарантка бенефициарның принципалга карата бирелгән таләп хокукларын үтәү йөзеннән алынган акчалар, бюджет кредитларын кире кайтару буларак чагылдырыла.

27. Муниципаль гарантияләр белән тәэмин ителгән кредитлар һәм займнар максатчан булырга тиеш.

28. Муниципаль гарантия белән тәэмин ителгән кредит (займ) акчаларын максатсыз файдалану факты ачыкланган очракта, муниципаль гарантия бирү турында шартнамәдә билгеләнгән йөкләмәләрне үтәмәгән яисә тиешенчә үтәмәгән очракта, принципал һәм бенефициар Россия Федерациясе законнарында, муниципаль гарантия бирү турында килешүдә билгеләнгән рәвештә җавап тота.

29. Бенефициарлары билгесез затлар булып торган йөкләмәләрне тәэмин итүдә бирелә торган муниципаль гарантиянең үзенчәлекләре Россия Федерациясе Бюджет кодексы белән билгеләнә.

30. Муниципаль кыйммәтле кәгазьләр эмиссиясе нәтиҗәсендә барлыкка килгән йөкләмәләр буенча муниципаль гарантияләрне бирү һәм үтәү үзенчәлекләре Россия Федерациясе Бюджет кодексы белән билгеләнә.

31. Муниципаль гарантияләрне бирү тәртибе һәм шартлары Россия Федерациясе Бюджет кодексы һәм аның нигезендә кабул ителгән әлеге карар белән билгеләнә.

**30 статья. Муниципаль кыйммәтле кәгазьләр**

1. Район исеменнән чыгарылган кыйммәтле кәгазьләр муниципаль кыйммәтле кәгазьләр дип танылa.

2. Муниципаль кыйммәтле кәгазьләрнең эмитенты булып Район Уставы муниципаль бурыч алуларны тормышка ашыру хокукына ия булган җирле хакимият тора.

3. Район тарафыннан чыгарылырга мөмкин булган муниципаль кыйммәтле кәгазьләрнең төрләре,аларның эмиссиясе тәртибе һәм шартлары, мөрәҗәгатьләре Россия Федерациясе Бюджет кодексы белән билгеләнә.

**31 статья. Район бюджетыннан бирелә торган бюджетара трансфертлар формалары**

Район бюджетыннан бюджетара трансфертлар формасында түбәндәгеләр бирелә:

җирлекләрнең бюджет тәэмин ителешен тигезләүгә район бюджетыннан дотацияләр;

Россия Федерациясе Бюджет Кодексының 142-142.4 статьяларында һәм Татарстан Республикасы Бюджет кодексының 44.9 статьясында билгеләнгән очракларда район бюджетыннан шәһәр, авыл җирлекләре бюджетларына субвенцияләр;

муниципаль берәмлекләр бюджетларына субсидияләр;

Татарстан Республикасы Бюджет кодексының 44.10 статьясында билгеләнгән очракларда Татарстан Республикасы бюджетына субсидияләр бирү;

башка бюджетара трансфертлар.

Район бюджетыннан шәһәр, авыл җирлекләре бюджетларына бюджетара трансфертлар (төзелгән килешүләр нигезендә җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү вәкаләтләренең бер өлешен гамәлгә ашыруга бюджетара трансфертлардан тыш) җирле үзидарә органнары тарафыннан шәһәр, авыл җирлекләре бюджетларына район бюджетыннан шәһәр, авыл җирлекләре бюджетларына бюджетара трансфертлар бирү кагыйдәләрендә билгеләнгән шартларны үтәгәндә бирелә.

Шәһәр, авыл җирлекләре бюджетларына дотацияләр исәпләү һәм бирү буенча Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары вәкаләтләрен гамәлгә ашыруга муниципаль районнар бюджетларына бирелә торган Татарстан Республикасы бюджеты, шул исәптән муниципаль районнар бюджетларына бирелә торган субвенцияләр исәбеннән район бюджетыннан шәһәр, авыл җирлекләре бюджетларына дотацияләр исәплү һәм бирү буенча бирелә торган бюджетара трансфертлар (субвенцияләрдән тыш) шәһәр, авыл җирлекләре бюджетларына Татарстан Республикасы бюджетыннан бюджетара трансфертлар бирүнең тиешле җирле үзидарә органнары тарафыннан Татарстан Республикасы Бюджет кодексының 44 статьясында каралган төп шартларын үтәгән очракта бирелә.

Федераль законнар һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә Балтач муниципаль районы бюджетына күчерелергә тиешле аерым салым булмаган керемнәрдән шәһәр, авыл җирлекләре бюджетларына керемнәр күчерү нормативларын билгеләү.

**32 статья. Җирлекләрнең бюджет тәэмин ителешен тигезләүгә район бюджетыннан дотацияләр бирү тәртибе**

1. Җирлекләрнең бюджет тәэмин ителешен тигезләүгә район бюджетыннан дотацияләр район составына керүче җирлекләргә Россия Федерациясе Бюджет кодексы таләпләре һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә кабул ителә торган район Советы карарлары нигезендә бирелә.

Җирлекләрнең бюджет тәэмин ителешен тигезләүгә район бюджетыннан дотацияләрнең гомуми күләме ел саен чираттагы финанс елына (чираттагы финанс елына һәм план чорына) район бюджеты проектын төзегәндә җирлекләрнең бюджет тәэмин ителешен тигезләүгә район составына керүче җирлекләр бюджетларына бирелә торган дотацияләрнең суммар күләме буларак билгеләнә һәм җирлекләрнең гомуми ихтыяҗлары һәм керем мөмкинлекләре бәяләрендәге аерманы һәм җирлекләрнең бюджет тәэмин ителешен тигезләүгә Татарстан Республикасы Бюджет кодексының 44.1 статьясындагы 5 пунктында билгеләнгән тәртиптә бирелә торган дотацияләрне исәпкә алып, җирлекләрнең хисап бюджет тәэмин ителешен тигезләү критериена ирешү зарурлыгыннан чыгып исәпләнелә.

Җирлекләрнең бюджет тәэмин ителешен тигезләүгә муниципаль берәмлекләр арасында, Татарстан Республикасы Бюджет кодексының 44.1 статьясындагы 5 пунктында билгеләнгән тәртиптә бирелә торган дотацияләрдән тыш, район бюджетыннан дотацияләрне бүлү, Татарстан Республикасы Бюджет кодексына 12 нче кушымта белән билгеләнгән тәртип нигезендә гамәлгә ашырыла.

2. Җирлекләрнең бюджет тәэмин ителешен тигезләүгә Район бюджетыннан дотацияләр күләме һәм аларны бүлү Чираттагы финанс елына (чираттагы финанс елына һәм план чорына) район бюджеты турында район Советы карары белән раслана.

Әгәр Район бюджеты проекты чираттагы финанс елына һәм план чорына расланса, план чорына шәһәр, авыл җирлекләре арасында план чорына Район бюджетыннан бюджет тәэмин ителешен тигезләүгә дотацияләр күләмен план чорының беренче елына расланган дотацияләрнең гомуми күләменнән 20 проценттан артмаган һәм план чорының икенче елына расланган күрсәтелгән дотацияләрнең гомуми күләменең 20 проценттан артмаган күләмен раслау рөхсәт ителә.

3. Җирлекләрнең бюджет тәэмин ителешен тигезләүгә Район бюджетыннан дотацияләр, Татарстан Республикасы Бюджет кодексының 44.1 статьясындагы 5 пунктында билгеләнгән тәртиптә бирелә торган дотацияләрдән тыш, хисаплы бюджет тәэмин ителеше Район шәһәр һәм

авыл җирлекләренең хисаплы бюджет тәэмин ителешен тигезләү критерие буларак билгеләнгән дәрәҗәдән артмаган шәһәр һәм авыл җирлекләренә бирелә.

Җирлекләрнең хисаплы бюджет тәэмин ителеше, шәһәр һәм авыл җирлеге бюджеты тарафыннан салым базасыннан (салым потенциалыннан) чыгып алынырга мөмкин булган бер кешегә салым керемнәренең һәм халык структурасындагы аермаларны, социаль-икътисадый, климат, географик һәм башка объектив факторларны һәм бер кешегә карата муниципаль хезмәт күрсәтүләр хакына тәэсир итә торган шартларны исәпкә алып, район җирлекләре буенча уртача күрсәткечкә охшаш күрсәткеч белән билгеләнә.

Бюджет тәэмин ителешенең исәп-хисап дәрәҗәсе шәһәр һәм авыл җирлекләре буенча шәһәр һәм авыл җирлекләренең салым керемнәре чагыштырмасын тәэмин итә торган бердәм методика буенча, бюджет хезмәтләре исемлеге һәм бер кешегә исәпләгәндә муниципаль хезмәтләр күрсәтү бәясенә тәэсир итә торган факторларны һәм шартларны характерлый торган күрсәткечләр исемлеге буенча билгеләнә, шәһәр һәм авыл җирлекләре өчен аерым билгеләнергә мөмкин.

Җирлекләрнең хисаплы бюджет тәэмин ителеше дәрәҗәсен билгеләгәндә, хисап чорында факттагы керемнәр һәм чыгымнар күрсәткечләрен һәм (яисә) аерым җирлекләрнең фаразлана торган керемнәре һәм чыгымнары күрсәткечләрен куллану рөхсәт ителми.

4. Әлеге статьяның 3 пунктында каралган дотацияләрне биргән очракта, районның финанс органы район бюджетыннан җирлекләрнең бюджет тәэмин ителешен тигезләүгә дотацияләр алучы муниципаль берәмлекләрнең җирле администрация башлыклары (башкарма-боеру органнары җитәкчеләре) белән җирлекләрнең социаль-икътисадый үсеше һәм җирлекнең муниципаль финансларын савыктыру чаралары каралган килешүләр төзергә хокуклы.

Әлеге пунктта күрсәтелгән килешүләр төзү тәртибе, сроклары һәм килешүләргә таләпләр җирле администрация (башкарма-боеру органы) тарафыннан билгеләнә.

**33 статья. Татарстан Республикасы бюджетына Район бюджетыннан субсидияләр**

1. Район бюджетыннан Татарстан Республикасы бюджетына субсидияләр Татарстан Республикасы Бюджет кодексының 44.10 статьясында билгеләнгән тәртиптә бирелә.

2. Әлеге статьяның 1 пунктында күрсәтелгән бюджетара субсидияләр Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы Законы нигезендә Район бюджетында карала.

**34 статья. Район бюджетыннан муниципаль берәмлекләр бюджетларына субсидияләр**

1. Район Советы карарларында каралган очракларда һәм тәртиптә Россия Федерациясе Бюджет кодексы таләпләре нигезендә Татарстан Республикасы Бюджет кодексы, башка муниципаль берәмлекләр бюджетларына җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча җирле үзидарә органнары вәкаләтләрен үтәгәндә барлыкка килә торган чыгым йөкләмәләрен финанслашу максатларында район бюджетыннан субсидияләр бирелергә мөмкин.

2. Әлеге статьяда күрсәтелгән субсидияләр бирүнең максатлары һәм шартлары Район Советы карары белән билгеләнгән тәртиптә төзелә торган җирле администрацияләр арасында килешүләр белән билгеләнә.

**35 статья. Район бюджетыннан шәһәр, авыл җирлекләре бюджетларына башка бюджетара трансфертлар**

Россия Федерациясе Бюджет кодексы, Татарстан Республикасы Бюджет кодексы һәм Татарстан Республикасының тиешле законнары нигезендә кабул ителә торган Район Советы карарларында каралган очракта һәм тәртиптә, Район бюджетыннан башка бюджетара трансфертлар, шул исәптән төзелгән килешүләр нигезендә җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү вәкаләтләренең бер өлешен гамәлгә ашыруга бюджетара трансфертлар да бирелергә мөмкин.

**36 статья. Район алдындагы акчалата йөкләмәләр**

1. Район алдындагы акчалата йөкләмә нигезендә билгеләнгән датага бурычлы тарафыннан түләнергә тиешле акчалар суммасы Район алдындагы акчалата йөкләмәләр буенча бурыч булып тора.

2. Район алдындагы акчалата йөкләмәләр буенча таләпләр Районның финанс активларын формалаштыра.

3. Акчалата йөкләмәләр буенча Район алдындагы бурычларны исәптән төшерү һәм торгызу кагыйдәләре (нигезләре, шартлары һәм тәртибе), Россия Федерациясе Бюджет кодексында каралган очраклардан тыш, җирлекнең Районның Финанс-бюджет палатасы тарафыннан билгеләнә.

4. Район алдындагы акчалата йөкләмәләрне (акчалата йөкләмәләр буенча бурычларны) һәм мондый йөкләмәләрне үтәүне тәэмин итә торган алыш-бирешләрне исәпкә алу, шулай ук күрсәтелгән йөкләмәләр һәм алыш-бирешләр буенча таләп хокукларын гамәлгә ашыру Россия Федерациясе Бюджет кодексының 932 статьясындагы 4 пунктында күрсәтелгән тиешле орган яисә Россия Федерациясе Бюджет кодексының 932 статьясындагы 5 пунктында күрсәтелгән вәкаләтле зат тарафыннан гамәлгә ашырыла.

5. Әгәр шартнамәдә башкача билгеләнмәгән булса, Район алдындагы акчалата йөкләмәләр тиешле акчалата сумманы Район бюджетының бердәм счетына күчергән көннән үтәлгән дип санала.

## II бүлек. БЮДЖЕТ ПРОЕКТЫН ТӨЗҮ

### 37 статья. Бюджет проектын төзү тәртибе һәм вакытлары

1. Бюджет проектын төзү - Район Башкарма комитетының аерым бер өстенлеге

Бюджет проектын турыдан-туры төзүне Районның Финанс-бюджет палатасы башкара. Бюджет проектын үз вакытында һәм сыйфатлы итеп төзү максатыннан Районның Финанс-бюджет палатасы башка җирле үзидарә органнарыннан кирәкле белешмәләр алырга хокуклы.

Бюджет проекты Россия Федерациясе Бюджет кодексы һәм аның таләпләрен үтәп кабул ителгән Татарстан Республикасы Бюджет кодексы, Район Уставы һәм бюджет проектын төзү тәртибе нигезендә Район Башкарма комитеты тарафыннан билгеләнгән тәртиптә һәм срокларда төзелә.

Бюджет проекты бер елга (чираттагы финанс елына) яки өч елга (чираттагы финанс елына һәм план чорына) төзелә һәм раслана.

2. Бюджет проектын төзү түбәндәгеләргә нигезләнә:

- Россия Федерациясе Президентының Бюджет юлламасына;

- Татарстан Республикасы Президентының Татарстан Республикасы Дәүләт Советына юлламасына;

- Районның социаль-икътисади үсеш фаразына;

- Районның бюджет һәм салым сәясәтенең төп юнәлешләренә;

- муниципаль программаларга;

- озак вакытлы чорга бюджет фаразы (бюджет фаразы проекты, бюджет фаразына үзгәрешләр проекты);

3. Бюджет проектын төзү өчен түбәндәге мәгълүматлар кирәк:

- салымнар һәм җыемнар турындагы закон проекты эшли башлаганда гамәлдә булган Россия Федерациясенең салымнар һәм җыемнар турындагы законнары, Татарстан Республикасының салымнар һәм җыемнар турындагы законнары, Район Советының норматив-хокукый актлары хакында;

- бюджетка федераль, региональ, җирле салымнардан һәм җыемнардан, махсус салым режимнарында каралган салымнардан күчерү нормативлары турында;

- Россия Федерациясе бюджет системасының башка дәрәҗәләре бюджетларыннан бирелә торган күчерүләрнең өстәмә нормативлары буенча салым керемнәренең һәм (яисә) түләүсез керемнәрнең күздә тотылган күләмнәре турында;

- Россия Федерациясе бюджет системасының башка дәрәҗәләреннән тапшырыла торган чыгымнарның төрләре һәм күләмнәре турында;

- муниципаль хезмәтләр күрсәтүгә финанс чыгымнарының нормативлары турында.

**38 статья. Социаль-икътисадый үсеш фаразы**

1. Районның социаль-икътисади үсеш фаразы Район Башкарма комитеты билгеләгән тәртиптә ел саен өч елдан да ким булмаган вакыт чорына эшләнә.

Районның социаль-икътисади үсеш фаразы Район Советы каравына 15 ноябрьдән дә соңга калмыйча Район Башкарма комитеты җитәкчесе тарафыннан кертелә.

Бюджет проектын төзү һәм карау барышында Районның социаль-икътисади үсеш фаразын үзгәртү бюджет проектының төп характеристикаларын үзгәртүгә китерә.

Районның социаль-икътисади үсеш фаразы макроикътисади вазгыять үсешенең сан күрсәткечләрен һәм сыйфат характеристикаларын, җитештерү һәм куллану динамикасын, халыкның тормыш дәрәҗәсен һәм сыйфатын һәм башка күрсәткечләрне үз эченә ала.

2. Җирлекләрнең социаль-икътисади үсеш фаразы Район Башкарма комитеты һәм җирлекләрнең башкарма комитетлары арасындагы килешүләр нигезендә Район Башкарма комитеты тарафыннан эшләнергә мөмкин.

**39 статья. Уртача вакытлы финанс планы**

1. Әгәр бюджет проекты чираттагы финанс елына төзелә һәм раслана икән, Район Башкарма комитеты Районның уртача сроклы финанс планын эшли һәм раслый.

2. Районның уртача вакытка исәпләнгән финанс планы, Россия Федерациясе Бюджет кодексы нигезләмәләрен үтәп, бюджетның төп параметрларын үз эченә алган документ булып тора.

3. Уртача сроклы финанс планы проекты Район Советына бюджет проекты белән бер үк вакытта тапшырыла.

**40 статья. Бюджет керемнәрен фаразлау**

1. Бюджет керемнәре, җирле бюджетның салым булмаган керемнәрен билгели торган, Россия Федерациясенең Салымнар һәм җыемнар, бюджет законнары, Татарстан Республикасы законнары һәм Район Советы карарларының бюджет турында карар проекты кертү көненә гамәлдә булган шартларда, районның социаль-икътисади үсеш фаразлары нигезендә фаразлана.

2. Бюджет керемен (чыгымын) үзгәртүгә китерә торган, Район Советына бюджет турында карар проектын керткәннән соң кабул ителгән,Район Советының салымнар һәм җыемнар турындагы норматив-хокукый актларына үзгәрешләр кертүне күздә тоткан Район Советы норматив-хокукый актлары, чираттагы финанс елыннан соң килгән елның 1 гыйнварына, район Советы норматив хокукый актларының үз көченә керүе турындагы нигезләмәләрне үз эченә алырга тиеш.

**41 статья. Бюджет ассигнованиеләрен планлаштыру**

1. Бюджет ассигнованиеләрен планлаштыру Районның Финанс-бюджет палатасы (бюджеттан тыш дәүләт фонды белән идарә итү органы) тарафыннан билгеләнгән методика нигезендә һәм тәртиптә тормышка ашырыла.

2. Бюджет ассигнованиеләрен планлаштыру гамәлдәге һәм кабул ителә торган йөкләмәләрне үтәүгә бюджет ассигнованиеләре буенча аерым гамәлгә ашырыла.

3. Бюджет һәм автоном учреждениеләр тарафыннан муниципаль хезмәтләр күрсәтүгә (эшләр башкаруга) бюджет ассигнованиеләрен планлаштыру, чираттагы финанс елына (чираттагы финанс елына һәм план чорына) муниципаль заданиене, шулай ук хисап финанс елында һәм агымдагы финанс елында аның үтәлешен исәпкә алып гамәлгә ашырыла.

**42 статья. Муниципаль программалар**

1. Районның муниципаль программалары (алга таба-муниципаль программалар) Район Башкарма комитеты тарафыннан раслана.

Муниципаль программаларны тормышка ашыру сроклары Район Башкарма комитеты тарафыннан алар билгеләгән тәртиптә билгеләнә.

Муниципаль программаларны эшләү һәм әлеге программаларны формалаштыру, тормышка ашыру турында карарлар кабул итү тәртибе Район Башкарма комитетының муниципаль хокукый акты белән билгеләнә.

2. Муниципаль программаларны гамәлгә ашыруны финанс белән тәэмин итүгә бюджет ассигнованиеләре күләме, программаны раслаган муниципаль хокукый акт нигезендә, бюджет чыгымнарының һәр максатчан статьясы буенча бюджет турындагы карар белән раслана.

Чираттагы финанс елыннан башлап тормышка ашырылырга тәкъдим ителгән муниципаль программалар, шулай ук элек расланган муниципаль программаларга үзгәрешләр Район Башкарма комитеты тарафыннан билгеләнгән срокларда расланырга тиеш.

Муниципаль программалар бюджет турындагы карар үз көченә кергән көннән алып ике айдан да соңга калмыйча туры китерелергә тиеш.

3. Районның һәр муниципаль программасы буенча ел саен аны тормышка ашыруның нәтиҗәлелеген бәяләү үткәрелә. Күрсәтелгән бәяләүне үткәрү тәртибе һәм аның критерийлары Район Башкарма комитеты тарафыннан билгеләнә.

Күрсәтелгән бәяләү нәтиҗәләре буенча Район Башкарма комитеты тарафыннан элек расланган муниципаль программаның чираттагы финанс елыннан башлап туктатылырга яки үзгәртергә, шул исәптән муниципаль программаны тормышка ашыруны финанс белән тәэмин итүгә бюджет ассигнованиеләре күләмен үзгәртү кирәклеге турында Карар кабул ителергә мөмкин.

**43 статья. Бюджет проектын төзү тәртибе һәм вакытлары**

Бюджет проектын төзү тәртибе һәм вакытлары, Россия Федерациясе Бюджет законнары, Татарстан Республикасы һәм Район Советының муниципаль хокукый актлары белән билгеләнгән таләпләрне үтәп, Район Башкарма комитеты тарафыннан билгеләнә.

## III бүлек. БЮДЖЕТ ТУРЫНДАГЫ КАРАРНЫ КАРАУ ҺӘМ РАСЛАУ

**44 статья. Гомуми нигезләмәләр**

1. Бюджет турындагы карарда бюджет керемнәренең гомуми күләме, чыгымнарның гомуми күләме, кытлык (профицит), шулай ук Россия Федерациясе Бюджет кодексында, Татарстан Республикасы законнарында, Районның хокукый актларында билгеләнгән башка күрсәткечләр (бюджет турындагы карарлардан тыш) кергән бюджетның төп характеристикалары булырга тиеш.

2. Бюджет турындагы карарда Россия Федерациясе Бюджет кодексы, Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы законнары һәм Россия Федерациясе Бюджет кодексы нигезләмәләре нигезендә кабул ителгән Район муниципаль хокукый актлары белән билгеләнмәгән очракта, җирлекләр бюджетлары арасында керемнәрне бүлү нормативлары булырга тиеш.

3. Бюджет турындагы карар белән түбәндәгеләр раслана:

- бюджет керемнәренең баш администраторлары исемлеге;

- бюджет кытлыгын финанслау чыганакларының баш администраторлары исемлеге;

-бюджет ассигнованиеләрен чыгымнар төрләре бүлекләре, бүлекчәләре, максатчан статьялары,төркемнәре (төркемнәре һәм төркемчәләре), чыгымнар төрләре бүлекләре, бүлекчәләре,максатчан статьялары (муниципаль программалар һәм эшчәнлек юнәлешләре), төркемнәре (төркемнәре һәм төркемчәләре) буенча һәм чираттагы финанс елына (чираттагы финанс елына һәм план чорына) бюджет чыгымнары классификациясенең чыгымнар төрләре, максатчан статьялары (муниципаль программалар һәм эшчәнлек юнәлешләре), төркемнәре (төркемнәре һәм төркемчәләре) буенча, шулай ук тиешле Россия Федерациясе Бюджет кодексы, Татарстан Республикасы законы, Район Советы хокукый актлары белән билгеләнгән очракларда бюджетлар чыгымнары классификациясенең бүлекләре һәм бүлекчәләре буенча бүлү;

- чираттагы финанс елына (чираттагы финанс елына һәм план чорына) бюджет чыгымнарының ведомство структурасы;

- гавами (ачык) норматив йөкләмәләрне үтәүгә юнәлдерелгән бюджет ассигнованиеләренең гомуми күләме;

- Чираттагы финанс елында (чираттагы финанс елында һәм план чорында) Россия Федерациясе бюджет системасының башка бюджетларыннан һәм (яисә) башка бюджетларына бирелә торган бюджетара трансфертлар күләме;

- чираттагы финанс елына һәм план чорының беренче елына бюджет расланса, шартлы рәвештә расланган (расланган) чыгымнарның гомуми күләме, план чорының беренче елына, бюджет чыгымнарының гомуми күләменең кимендә 2,5 проценты күләмендә (максатчан билгеләнеше булган Россия Федерациясе бюджет системасының башка бюджетларыннан бюджетара трансфертлар исәбеннән каралган бюджет чыгымнарын исәпкә алмыйча), һәм план чорының икенче елына, бюджет чыгымнарының гомуми күләменең кимендә 5 проценты күләмендә (максатчан билгеләнеше булган Россия Федерациясе бюджет системасының башка бюджетларыннан бюджетара трансфертлар исәбеннән каралган бюджет чыгымнарын исәпкә алмыйча);

- чираттагы финанс елына һәм план чорына бюджет кытлыгын финанслау чыганаклары (чираттагы финанс елына һәм план чорына);

- муниципаль эчке бурычның иң югары чиге һәм (яисә) муниципаль тышкы бурычның иң югары чиге, шул исәптән муниципаль гарантияләр буенча бурычның иң югары чиген күрсәтеп, чираттагы финанс елыннан һәм план чорының һәр елыннан соң килүче елның 1 гыйнварына булган торышы;

- бюджетның Россия Федерациясе Бюджет кодексы, Татарстан Республикасы законы, Районның хокукый актларында билгеләнгән башка күрсәткечләре.

4. Чираттагы финанс елына һәм план чорына бюджет турында карар проекты (өч елга кабул ителгән очракта) расланган бюджетның план чоры параметрларын үзгәртү һәм аларга бюджет проектының план чорының икенче ел параметрларын өстәү юлы белән раслана.

Бюджетның план чоры параметрларын үзгәртү Район Советының муниципаль хокукый акты нигезендә башкарыла.

Бюджет чыгымнарының ведомство структурасы күрсәткечләрен үзгәртү расланган бюджет ассигнованиеләрен арттыру яисә кыскарту яки бюджет чыгымнарының өстәмә максатчан статьялары һәм (яисә) төрләре буенча бюджет ассигнованиеләрен чыгымнар ведомство структурасына кертү юлы белән гамәлгә ашырыла.

5. Шартлы рәвештә расланган (расланган) чыгымнар дигәндә план чорында бюджет чыгымнары классификациясе нигезендә бүленмәгән бюджет ассигнованиеләре аңлашыла.

6. Бюджет турындагы карарда чираттагы финанс елыннан башлап гамәлгә кертергә (бюджетта чагылдырылырга) тәкъдим ителә торган салым булмаган керемнәрнең аерым төрләре (подвидлары) буенча бюджет керемнәрен бюджет турындагы карарда билгеләнгән максатларга тиешле бюджет ассигнованиеләреннән һәм (яисә) бюджет чыгымнарының гомуми күләменнән тыш файдалану каралырга мөмкин.

**45 статья. Бюджет проекты белән бер үк вакытта тапшырыла торган документлар һәм материаллар**

Бюджет турындагы карар проекты белән бер үк вакытта Район Советына түбәндәгеләр тапшырыла:

- бюджет һәм салым сәясәтенең төп юнәлешләре;

- агымдагы финанс елының узган чорында Районның социаль-икътисади үсешенең якынча нәтиҗәләре һәм агымдагы финанс елында Районның социаль-икътисади үсешенең көтелгән нәтиҗәләре;

- Районның социаль-икътисади үсеш фаразы;

- чираттагы финанс елына һәм план чорына берләштерелгән бюджетның төп характеристикалары фаразы (керемнәрнең гомуми күләме, чыгымнарның гомуми күләме, кытлык (профицит) яисә уртача вакытылы финанс планы);

- бюджет проектына аңлатма язуы;

- методикалар (методикалар проектлары) һәм бюджетара трансфертларны бүлүне исәплләү;

- чираттагы финанс елыннан һәм план чорының елыннан (чираттагы финанс елыннан) соң килә торган елның 1 гыйнварына булган торышы буенча муниципаль эчке бурычның иң югары чиге һәм муниципаль тышкы бурычның иң югары чиге;

- агымдагы финанс елына бюджетның көтелгән үтәлешен бәяләү;

- Район Советы, суд системасы, Районның Контроль-хисап палатасы тарафыннан тәкъдим ителгән, әлеге бюджет сметаларына карата Районның Финанс-бюджет палатасы белән каршылыклар килеп чыккан очракта тапшырыла торган, әлеге органнарның бюджет сметалары проектлары;

- Россия Федерациясе Бюджет кодексы, Татарстан Республикасы Бюджет кодексы, муниципаль хокукый актларда билгеләнгән башка документлар һәм материаллар.

Муниципаль программалар һәм эшчәнлекнең программалы булмаган юнәлешләре буенча бюджет ассигнованиеләрен бүлү бюджеты турындагы карар расланган очракта, бюджет турындагы карар проектына муниципаль программалар паспортлары тапшырыла.

Әгәр бюджет турындагы карар проектында бюджет чыгымнарын классификацияләү бүлекләре һәм бүлекчәләре буенча бюджет ассигнованиеләрен бүлү турында кушымта булмаса, бюджет чыгымнарын классификацияләү бүлекләре һәм бүлекчәләре буенча бюджет ассигнованиеләрен бүлү хакында кушымта бюджет турындагы карар проектының аңлатма язуының кушымталар составына кертелә.

**46 статья. Бюджет турындагы карар проектын карау**

1. Район башкарма комитеты, агымдагы елның 15 ноябреннән дә соңга калмыйча, чираттагы финанс елына (чираттагы финанс елына һәм план чорына) бюджет турындагы карар проектын Район Советы каравына кертә.

Бюджет турындагы карар проекты Район Советына кертелгәннән соң 3 (өч) эш көне дәвамында Район Советы рәисе аны Район Контроль-хисап палатасына экспертиза үткәрү өчен җибәрә.

Районның Контроль-хисап палатасы 5 (биш) эш көне дәвамында бюджет турындагы карар проекты хакында, ачыклаган очракта җитешсезлекләрне күрсәтеп, бәяләмә әзерли.

Районның Контроль-хисап палатасы бәяләмәсе Район Советы депутатлары тарафыннан бюджет турындагы карар проектына төзәтмәләр әзерләгәндә исәпкә алына.

2.Кертелгән бюджет турындагы карар проекты, Районның Контроль-хисап палатасы бәяләмәсе белән, бюджет формалаштыру, икътисад һәм социаль-икътисади үсешне фаразлау комиссиясенә, шулай ук район Советы депутатларына карап тикшерү өчен җибәрелә.

3. Бюджет турындагы карар проекты Район Контроль-хисап палатасы бәяләмәсе белән бюджетны формалаштыру, икътисад һәм социаль-икътисадый үсешне фаразлау комиссиясенә, шулай ук Район Советы депутатларына җибәрелгәннән соң, бер атна эчендә Бюджет турындагы карар проектының беренче укылышы үткәрелә.

Беренче укылышның предметы булып бюджет турындагы карар проектының төп параметрларын хуплау тора.

4. Икенче укылышта бюджет турындагы карар проекты тулысынча кабул ителә.

5. Бюджет турындагы карар проекты буенча килештермәгән сораулар килеп туган очракта, Район Советы рәисе карары белән килештерү комиссиясе төзелергә мөмкин, аңа тигез санда Район Башкарма комитеты һәм Район Советы вәкилләре керә.

Килештерү комиссиясе район Советы Рәисе тарафыннан расланган регламент нигезендә бюджет турындагы карар проектының беренче һәм икенче укылышлары арасындагы бәхәсле мәсьәләләрне карый.

6. Район Советы кабул иткән бюджет турындагы карар 5 (биш) эш көне эчендә Район Советы рәисенә имзалау өчен җибәрелә.

7. Бюджет турындагы карар аңа кул куйганнан соң җиде көннән дә соңга калмыйча билгеләнгән тәртиптә рәсми бастырып чыгарылырга тиеш.

**47 статья. Бюджет турындагы карарны раслау вакытлары һәм чираттагы финанс елына (чираттагы финанс елына һәм план чорына) бюджет турындагы карар проектын үз вакытында кабул итмәү нәтиҗәләре**

1. Бюджет турындагы карар Район Советы тарафыннан расланган, Район Советы рәисе тарафыннан имзаланган һәм чираттагы финанс елы башланганчы басылып чыккан булырга тиеш.

Районның җирле үзидарә органнары үз компетенциясе кысаларында бюджет турында кабул ителгән карарны үз вакытында карауны, раслауны, имзалауны һәм бастырып чыгаруны тәэмин итү буенча мөмкин булган барлык чараларны күрергә бурычлы.

2. Әгәр чираттагы финанс елына (чираттагы финанс елына һәм план чорына) бюджет турындагы карар финанс елы башыннан үз көченә кермәсә, Россия Федерациясе Бюджет кодексы белән билгеләнгән кысаларда бюджет белән вакытлыча идарә итү режимы кертелә.

## IV бүлек. БЮДЖЕТ ҮТӘЛЕШЕ

**48 статья. Бюджет үтәлешенең нигезләре**

1. Бюджет үтәлеше Район Башкарма комитеты тарафыннан тәэмин ителә.

2. Бюджет үтәлешен оештыру Районның Финанс-бюджет палатасына йөкләнә.

3. Бюджет үтәлеше җыелма бюджет язмасы нигезендә оештырыла, ул кабул ителгән бюджетка һәм касса планына туры килергә тиеш.

Бюджет кассаның бердәмлеге һәм чыгымнарның ведомствога буйсынуы нигезендә башкарыла.

Бюджет үтәлешенең касса хезмәте ОФК һәм ТОДК тарафыннан башкарыла.

4. Җыелма бюджет язмасын төзү һәм алып бару, аңа үзгәрешләр кертү тәртибе Россия Федерациясе Бюджет кодексы нигезендә Районның Финанс-бюджет палатасы тарафыннан билгеләнә һәм бюджет акчаларының баш бүлүчеләре (бүлүчеләр) һәм алучылары игътибарына җиткерелә.

5. Районның Финанс-бюджет палатасы касса планын төзү һәм алып бару тәртибен, шулай ук бюджет акчаларының баш бүлүчеләре (бүлүчеләр), бюджет керемнәренең баш администраторлары (администраторлары), бюджет кытлыгын финанслау чыганакларының баш администраторлары (администраторлары) тарафыннан касса планын төзү һәм алып бару өчен кирәкле белешмәләрнең составын һәм вакытын билгели.

Касса планын төзү һәм алып бару Районның Финанс-бюджет палатасы тарафыннан башкарыла.

**49 статья. Керемнәр буенча бюджет үтәлеше**

Керемнәр буенча бюджет үтәлеше түбәндәгеләрне күздә тота:

-агымдагы финанс елында Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы бюджет законнары һәм муниципаль хокукый актлар белән билгеләнгән,гамәлдәге нормативлар буенча бүленә торган, ОФК счетларыннан һәм бюджетка башка кертемнәрдән Россия Федерациясе бюджет системасына салымнарны, җыемнарны һәм башка керемнәрне бүлүдән барлыкка килгән керемнәрне бюджетның бердәй счетына күчерүне;

- артык бүленгән суммаларны күчерү, артык түләнгән яки артык алынган суммаларны кире кайтару, шулай ук андый кире кайтаруны вакытында башкармаган өчен процентлар һәм артык алынган суммаларга исәпләнгән процентлар суммаларын кире кайтаруны;

- артык түләнгән яки артык алынган салымнар, җыемнар һәм башка түләүләр суммаларын кире кайтаруны (зачетны, төгәлләштерүне) тормышка ашыру өчен кирәкле артык бүленгән суммаларны, чараларны, шулай ук мондый кире кайтаруны үз вакытында башкармаган өчен процентлар суммаларын һәм артык алынган суммаларга исәпләнгән процентларны Россия Федерациясе Бюджет кодексы нигезендә җирле бюджетның бердәм счетыннан күчерүне;

- Россия Федерациясенең салымнар һәм җыемнар турындагы законнары нигезендә артык түләнгән яисә артык алынган суммалары хисабын;

- керемнәрнең баш администраторы (администраторы) тарафыннан бюджетка түләүләрне аныклавын.

**50 статья. Чыгымнар буенча бюджет үтәлеше**

1. Бюджетның чыгымнар буенча үтәлеше, Россия Федерациясе Бюджет кодексы таләпләрен үтәп, Районның Финанс-бюджет палатасы тарафыннан билгеләнгән тәртиптә тормышка ашырыла.

2. Бюджетның чыгымнар буенча үтәлеше түбәндәгеләрне күздә тота:

- Бюджет йөкләмәләрен кабул итүне;
- акча йөкләмәләрен раслауны;
- акчалата йөкләмәләрне түләүне санкцияләүне;
- акчалата йөкләмәләрнең үтәлешен раслауны.

Бюджет акчаларын алучы бюджет йөкләмәләрен аңа җиткерелгән бюджет йөкләмәләре лимитлары чикләрендә кабул итә.

Бюджет акчаларын алучы бюджет йөкләмәләрен муниципаль шартнамәләр (договорлар), физик һәм юридик затлар, шәхси эшмәкәрләр белән башка шартнамәләр (договорлар) төзү яисә закон нигезендә башка хокукый акт, килешү төзү юлы белән кабул итә.

3. Бюджет акчаларын алучы  түләүне санкцияләү өчен кирәкле түләү һәм башка документлар нигезендә акча йөкләмәләрен бюджет акчалары исәбеннән түләү бурычын раслый.

4. Акчалата йөкләмәләрне түләүне санкцияләү рөхсәт язуын (акцепт) башкару рәвешендә, бюджет законнары нигезләмәләре нигезендә, Районның Финанс-бюджет палатасы тарафыннан билгеләнгән акчалата йөкләмәләрне түләүне санкцияләү тәртибендә каралган документларның булу-булмавын тикшергәннән соң гамәлгә ашырыла.

5. Акчалата йөкләмәләрне үтәүне раслау физик яисә юридик затлар, Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетлары файдасына бюджетның бердәм счетыннан акчаларны исәптән төшерүне раслый торган түләү документлары нигезендә, шулай ук бюджет акчаларын алучыларның акчалата йөкләмәләрен үтәү буенча акчалата булмаган операцияләр уздыруны раслый торган башка документлар нигезендә гамәлгә ашырыла.

**51 статья. Бюджет язмасы**

1. Бюджет акчаларының баш бүлүчеләренең (бүлүчеләрнең) бюджет язмаларын төзү һәм алып бару тәртибе, аларга үзгәрешләр кертүне дә кертеп, Районның Финанс-бюджет палатасы тарафыннан билгеләнә.

2. Бюджет акчаларының баш бүлүчеләренең (бүлүчеләрнең) бюджет язмалары җыелма бюджет язмасы белән расланган бюджет ассигнованиеләре һәм Районның Финанс-бюджет палатасы җитәкчесе тарафыннан расланган бюджет йөкләмәләре лимитлары нигезендә төзелә.

Бюджет акчаларының баш бүлүчеләренең (бүлүчеләрнең) бюджет язмалары бюджет ассигнованиеләре һәм аларга җиткерелгән бюджет йөкләмәләре лимитлары нигезендә төзелә.

Бюджет язмасын раслау һәм аңа үзгәрешләр кертү бюджет акчаларының баш бүлүчесе (бүлүче) тарафыннан гамәлгә ашырыла.

3. Чыгымнар буенча бюджет язмасы күрсәткечләре, бюджет законнарында каралган очраклардан тыш, чираттагы финанс елы башына кадәр, ведомствога караган бюджет акчаларының бүлүчеләренә һәм (яисә) бюджет акчаларын алучыларга җиткерелә.

4. Бюджет язмаларын төзү һәм алып бару тәртибе бюджет акчаларының баш бүлүчесенең (бүлүченең) бюджет язмасы белән раслана торган чыгымнар төрләре элементлары (төркемчәләре һәм элементлары) кодлары, шулай ук дәүләт идарәсе секторы операцияләрен классификацияләү кодлары буенча күрсәткечләрне детальләштерүне гамәлгә ашыру хокукын яисә бурычын билгеләргә мөмкин.

5. Җыелма бюджет язмасы күрсәткечләре нигезендә бюджет акчаларының баш бүлүченең чыгымнары буенча бюджет язмасы белән расланган күрсәткечләрне җыелма бюджет язмасына тиешле үзгәрешләр кертмичә үзгәртү рөхсәт ителми.

Бюджет акчаларының баш бүлүчесенең бюджет язмасы күрсәткечләре нигезендә бюджет акчаларының бүлүчесенең чыгымнары буенча бюджет язмасы белән расланган күрсәткечләрне бюджет акчаларының баш бүлүчесенең бюджет язмасына тиешле үзгәрешләр кертмичә үзгәртү рөхсәт ителми.

**52 статья. Бюджет кытлыгын финанслау чыганаклары буенча бюджет үтәлеше**

Бюджет кытлыгын финанслау чыганаклары буенча бюджет үтәлеше бюджет законнарының нигезләмәләре нигезендә Районның Финанс-бюджет палатасы тарафыннан билгеләнгән тәртиптә бюджетның бердәм счетында калган акчалар белән идарә итү операцияләреннән тыш, җыелма бюджет язмасы нигезендә баш администраторлар, администраторлар тарафыннан гамәлгә ашырыла.

Бюджет кытлыгын финанслау чыганаклары буенча бюджет ассигнованиеләре исәбеннән үтәлергә тиешле акчалата йөкләмәләрне түләүне санкцияләү Районның Финанс-бюджет палатасы билгеләгән тәртиптә гамәлгә ашырыла.

**53 статья. Агымдагы финанс елының тәмамлануы**

1. Россия Федерациясе Бюджет кодексының 242 статьясындагы 2 пунктында күрсәтелгән операцияләрдән тыш, бюджет үтәлеше буенча операцияләр 31 декабрьдә тәмамлана.
Агымдагы финанс елында бюджет үтәлеше буенча операцияләрне төгәлләү, Россия Федерациясе Бюджет кодексы һәм әлеге статья таләпләре нигезендә, Районның Финанс-бюджет палатасы тарафыннан билгеләнгән тәртиптә гамәлгә ашырыла.

2. Агымдагы финанс елының бюджет ассигнованиеләре, бюджет йөкләмәләре лимитлары һәм финанслауның иң чик күләмнәре 31 декабрьдә үз көчләрен югалталар.

3. Бюджет акчаларын алучылар тарафыннан бюджетның бердәм счетында кулланылмаган бюджет акчалары калдыклары, агымдагы финанс елының соңгы ике эш көненнән дә соңга калмыйча, бюджет акчаларын алучылар тарафыннан бюджетның бердәм счетына күчерелергә тиеш.

4. Максатчан билгеләнеше булган субсидияләр, субвенцияләр һәм башка бюджетара трансфертлар рәвешендә агымдагы финанс елында файдаланылмаган бюджетара трансфертлар бюджет кеременә кире кайтарылырга тиеш.

Бюджет акчаларының баш администраторының карары нигезендә, агымдагы финанс елында файдаланылмый торган субсидияләр һәм башка бюджетара трансфертлар рәвешендә алынган бюджетара трансфертларга ихтыяҗ булу турындагы карар нигезендә, күрсәтелгән бюджетара трансфертларның калдыгыннан артмаган күләмдә акчалар алдагы финанс елында күрсәтелгән бюджетара трансфертларны бирү максатларына тиешле бюджет чыгымнарын финанс белән тәэмин итү өчен бирелгән чираттагы финанс елында бюджетка кире кайтарылырга мөмкин.

Максатчан билгеләнештәге субсидияләр, субвенцияләр һәм башка бюджетара трансфертлар рәвешендә алынган файдаланылмаган бюджетара трансфертлар калдыгы бюджет кеременә күчерелмәгән очракта, әлеге акчалар, Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән гомуми таләпләрне үтәп, Районның Финанс-бюджет палатасы билгеләгән тәртиптә, бюджет кеременә күчерелергә тиеш.

5. Районның Финанс-бюджет палатасы агымдагы финанс елы тәмамланганда бюджет акчаларын алучыларны чираттагы финанс елының гыйнварында Россия Федерациясендә эш булмаган бәйрәм көннәрендә аларның эшчәнлеген гамәлгә ашыру өчен кирәкле акчалар белән тәэмин итү тәртибен билгели.

## V бүлек. БЮДЖЕТ ХИСАПЛЫЛЫГЫН ТӨЗҮ, ТЫШКЫ ТИКШЕРҮ, КАРАУ ҺӘМ РАСЛАУ

**54 статья. Бюджет исәбе һәм бюджет үтәлеше турында хисап**

1. Бюджет исәбенең һәм бюджет хисаплылыгының бердәм методологиясе һәм стандартлары бюджет законнары нигезләмәләре нигезендә Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнә.

2. Бюджет хисаплылыгы түбәндәгеләрне үз эченә ала:
1) бюджет үтәлеше турында хисапны;
2) бюджет үтәлеше балансын;

3) эшчәнлекнең финанс нәтиҗәләре турында хисапны;

4) акча хәрәкәте турында хисапны;

5) аңлатма язуын.

2. Районның бюджет хисаплылыгы бюджет акчаларының тиешле баш администраторларының (администраторларының) җыелма бюджет хисаплылыгы нигезендә Районның Финанс-бюджет палатасы тарафыннан төзелә.

3. Районның бюджет хисаплылыгы еллык хисап булып тора. Бюджет үтәлеше турындагы хисап квартал саен була.

4. Районның бюджет хисаплылыгы Районның Финанс-бюджет палатасы тарафыннан Район Башкарма комитетына тапшырыла.

Агымдагы финанс елының беренче кварталында, ярты еллыгында һәм тугыз аенда бюджет үтәлеше турындагы хисап Район Башкарма комитеты тарафыннан раслана һәм Район Советына, Районның Контроль-хисап палатасына хисап тапшыру вакыты чыкканнан соң ун көннән дә соңга калмыйча җибәрелә.

Бюджет үтәлеше турындагы еллык хисап Район Советы карары белән расланырга тиеш.

**55 статья. Бюджет үтәлеше турындагы еллык хисапны тышкы тикшерү**

1. Район Советында караганчы бюджет үтәлеше турындагы еллык хисап, бюджет акчаларының баш администраторларының (администраторларының) бюджет хисабын тышкы яктан тикшерүне һәм бюджет үтәлеше турында еллык хисапка бәяләмә әзерләүне үз эченә алган тышкы тикшерү узарга тиеш.

2. Бюджет үтәлеше турындагы еллык хисапны тышкы тикшерү, Россия Федерациясе Бюджет кодексы таләпләрен үтәп һәм федераль законнарда билгеләнгән үзенчәлекләрне исәпкә алып, Район Советының муниципаль хокукый актында билгеләнгән тәртиптә, Район Контроль-хисап палатасы тарафыннан гамәлгә ашырыла.

3. Район Башкарма комитеты агымдагы елның 1 апреленнән дә соңга калмыйча Районның Контроль-хисап палатасына бюджет үтәлеше турында хисап тапшыра. Район бюджеты үтәлеше турындагы еллык хисапка бәяләмә әзерләү бер айдан да артмаган вакытта башкарыла. Бюджет үтәлеше турындагы хисапка бәяләмә бюджет акчаларының баш администраторларының (администраторларнын) еллык бюджет хисаплылыгын тышкы тикшерү мәгълүматлары нигезендә әзерләнә.

4. Бюджет үтәлеше турындагы еллык хисапка бәяләмә Район Советына һәм Район башкарма комитетына Контроль-хисап палатасы тарафыннан тапшырыла.

**56 статья. Район Советына бюджет үтәлеше турында хисап бирү**

1. Ел саен 1 майдан да соңга калмыйча Район Башкарма комитеты җитәкчесе Район Советына финанс хисап елы өчен бюджет үтәлеше турында хисап тапшыра.

2. Бюджет үтәлеше турындагы хисап белән бер үк вакытта түбәндәгеләр тапшырыла:

- хисап финанс елына бюджет үтәлеше турында карар проекты;
- бюджет үтәлеше балансы;
- эшчәнлекнең финанс нәтиҗәләре турында хисап;
- акча хәрәкәте турында хисап;
- бюджет үтәлеше турында аңлатма язуы;
- узган финанс елында Районның социаль-икътисади үсеше турында хисап;
- Район Башкарма комитетының резерв фонды ассигнованиеләреннән файдалану турында хисап;
- бюджеттан бирелгән бюджет кредитларын бирү һәм түләү турында хисап;
- муниципаль гарантияләр турында белешмәләр;
- бурыч алуларның төрләре буенча муниципаль бурыч алулар турында белешмәләр;
- муниципаль бурыч структурасы турында мәгълүматлар;
- муниципаль милекне кулланудан алынган керемнәр турында мәгълүматлар;
- Россия Федерациясе бюджет законнарында каралган башка хисап.

3. Район Советы утырышында Район Башкарма комитеты җитәкчесенең бюджет үтәлеше турындагы доклады, шулай ук районның Контроль-хисап палатасы җитәкчесе докладлы тыңлана.

4. Район Советы Бюджет үтәлеше турындагы хисапны раслау һәм Район Советы тарафыннан тиешле карар кабул итү яки бюджет үтәлеше турындагы карарны кире кагу хакында карар кабул итә.

5. Район Советы Бюджет үтәлеше турындагы карарны кире каккан очракта, дөрес булмаган яки тулы чагылдырылмаган мәгълүматларны бетерү һәм бер айдан артмаган вакыт эчендә кабат тапшыру өчен ул кире кайтарыла.

**57 статья. Бюджет үтәлеше турындагы карар**

Бюджет үтәлеше турындагы карар нигезендә хисап финанс елына бюджет үтәлеше турындагы хисап, бюджет керемнәренең, чыгымнарның һәм кытлыкның (профицитның) гомуми күләмен күрсәтеп, раслана.

Хисап финанс елында Район бюджеты үтәлеше турындагы карарга аерым кушымталар белән түбәндәге күрсәткечләр раслана:

- район бюджеты керемнәрен классификацияләү кодлары буенча бюджет керемнәре;
- керем төрләренең кодлары, керемнәрнең төрләре, керемнәрнең подвидлары, бюджет керемнәренә керүче Дәүләт идарәсе секторы операцияләрен классификацияләү;
- бюджет чыгымнарының ведомство структурасы буенча бюджет чыгымнары;
- чыгымнарны классификацияләү бүлекләре һәм бүлекчәләре буенча бюджет чыгымнары;
- бюджет кытлыгын финанслау чыганакларының классификациясе кодлары буенча бюджет кытлыгын финанслау чыганаклары;
- бюджетлар кытлыкларын финанслау чыганакларына карый торган дәүләт идарәсе секторының операцияләре классификациясенең бюджетлар кытлыкларын финанслау чыганаклары төркемнәренең, төркемчәләренең, статьяларының, төрләренең кодлары буенча бюджет финанслау чыганаклары.

Бюджет үтәлеше турындагы карарда бюджет үтәлеше турында карар кабул итү өчен бюджет законнары һәм Район Советының муниципаль хокукый актлары белән билгеләнгән башка күрсәткечләр раслана.

## VI бүлек. МУНИЦИПАЛЬ ФИНАНС КОНТРОЛЕ

**58 статья. Муниципаль финанс контролен гамәлгә ашыручы органнар**

1. Тышкы муниципаль финанс контроле бюджет хокук мөнәсәбәтләре өлкәсендә Район Контроль-хисап палатасының контроль эшчәнлеге булып тора.

2. Бюджет хокук мөнәсәбәтләре өлкәсендә эчке муниципаль финанс контроле-Районның Финанс-бюджет палатасының контроль эшчәнлеге.

3. Муниципаль финанс тикшерүе органнарының бюджет вәкаләтләре Россия Федерациясе Бюджет кодексы нигезендә билгеләнә.

**59 статья. Бюджет хокук бозулары өчен җаваплылык**

Бюджет хокук бозулары өчен җаваплылык Россия Федерациясе Бюджет кодексында һәм башка федераль законнарда каралган рәвешләрдә барлыкка килә.